| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

21.12.2017 Казан ш. № 3008-р

**Татарстан Республикасының Апас, Буа, Чүпрәле, Кайбыч, Кама Тамагы, Тәтеш муниципаль районнары территориясендәге газ бүлгеч челтәрләренең (газүткәргечләр) саклык зоналары чикләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары чикләрен раслау турында карарлар кабул итү тәртибен раслау һәм аларга керә торган җир кишәрлекләренә чикләүләр (йөкләүләр) кертү турында” 30.04.2014 № 288 карарына туры китереп һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате һәм газ бүлү челтәрләренә милек хокукын раслаучы документлар нигезендә, һәм «Геоконсалтинг» ҖЧҖ башкарган документациягә туры китереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы) КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Газ бүлү челтәрләренең (газүткәргечләрнең) саклау зоналары чикләрен расларга:

1.1. Апас муниципаль районы территориясендә урнашкан 13,624 км озынлыктагы, территориясе 0,054496 кв.км гомуми мәйданлы, әлеге карарга 1

нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы ЭПУ «Буинскгаз» газ бүлү газ үткәргечен - «Геоконсалтинг» ҖЧҖ тарафыннан 2017 елның 18 сентябреннән 2017 елның 30 октябренә кадәр башкарылган һәм 2017 елның 1 ноябендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ белән килештерелгән территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлеге буенча.

1.2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә урнашкан 13,864 км озынлыктагы, территориясе 0,054496 кв.км гомуми мәйданлы, әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы ЭПУ «Буинскгаз» газ бүлү газ үткәргечен - «Геоконсалтинг» ҖЧҖ тарафыннан 2017 елның 18 сентябреннән 2017 елның 30 октябренә кадәр башкарылган һәм 2017 елның 1 ноябендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ белән килештерелгән территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлеге буенча.

1.3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә урнашкан 1,911 км озынлыктагы, территориясе 0,007644 кв.км гомуми мәйданлы, әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы ЭПУ «Буинскгаз» газ бүлү газ үткәргечен - «Геоконсалтинг» ҖЧҖ тарафыннан 2017 елның 18 сентябреннән 2017 елның 30 октябренә кадәр башкарылган һәм 2017 елның 1 ноябендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ белән килештерелгән территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлеге буенча.

1.4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә урнашкан 41,369 км озынлыктагы, территориясе 0,159049 кв.км гомуми мәйданлы, әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы ЭПУ «Буинскгаз» газ бүлү газ үткәргечен - «Геоконсалтинг» ҖЧҖ тарафыннан 2017 елның 18 сентябреннән 2017 елның 30 октябренә кадәр башкарылган һәм 2017 елның 1 ноябендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ белән килештерелгән территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлеге буенча.

1.5. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы территориясендә урнашкан 9,958 км озынлыктагы, территориясе 0,039832 кв.км

гомуми мәйданлы, әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы ЭПУ «Буинскгаз» газ бүлү газ үткәргечен - «Геоконсалтинг» ҖЧҖ тарафыннан 2017 елның 18 сентябеннән 2017 елның 30 октябренә кадәр башкарылган һәм 2017 елның 1 ноябендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ белән килештерелгән территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлеге буенча.

1.6. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы территориясендә урнашкан 20,824 км озынлыктагы, территориясе 0,083296 кв.км гомуми мәйданлы, әлеге карарга 1 нче кушымтада күрсәтелгән инвентарь номерлы ЭПУ «Буинскгаз» газ бүлү газ үткәргечен - «Геоконсалтинг» ҖЧҖ тарафыннан 2017 елның 18 сентябеннән 2017 елның 30 октябренә кадәр башкарылган һәм 2017 елның 1 ноябендә «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ белән килештерелгән территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, газ бүлү челтәре чикләренең характерлы нокталарының координаталары исемлеге буенча.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән һәм әлеге карарның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә газ бүлү челтәрләрен эксплуатацияләү срогына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖенә тәкъдим итергә:

1) газүткәргечнең саклау зоналары турында мәгълүматларны Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертү чараларын күрергә;

2) әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары чикләренә кергән һәм әлеге карарның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә булган чикләүләрне Күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешкә хокуклар бердәм дәүләт реестрына кертү чараларын күрергә;

3) әлеге карар кабул ителүгә 10 көн эчендә аны һәм әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән газүткәргечләрнең саклау зоналары җир төзелеше объектлары карталарын (план) XML-схемалар кулланып төзелгән һәм бирелгән мәгълүматның укылышын һәм контролен тәэмин итүче XML форматындагы файллар рәвешендә, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән

газүткәргечләрнең саклау зоналары турында һәм әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә булган чикләүләрне күчемсез милек дәүләт кадастрына кертү өчен «ФКП Росреестр»ның Татарстан Республикасы буенча филиалына юлларга.

4. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны җир ресурслары идарәсе башлыгы Э.Г. Миндубаевка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**